БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__21__» ___01____ 2020 г. № _39____

**Балтач муниципаль районында ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләрен хәл итү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районында ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне раcларга (1 нче кушымта)
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының
2020 елның ___________
______ номерлы карары белән расланды

Балтач муниципаль районында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә.

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы каршындагы даими эшләүче, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары белән, граждан җәмгыяте институтлары белән, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеген координацияләүне һәм оештыруны тәэмин итә торган координация органы булып тора.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә ярдәм күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы Нигезләмәгә таяна.

1.3. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге яңадан социальләштерүгә ярдәм итү күздә тотыла торган затларның теләк белдерүләре ихтыярлылык һәм иреклелек принципларына нигезләнә.

II. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үтәгән затлар һәм (яки) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга, шул исәптән түбәндә санап кителгән чараларга тартылган затларны җәмгыятькә реинтеграцияләү максатларында социаль-икътисадый, педагогик, хокукый характердагы чаралар комплексын гамәлгә ашыру:

постпенитенциар ярдәм күрсәтү;

һөнәри юнәлеш бирү һәм хезмәткә яраклаштыру (адаптация);

торак ягыннан һәм көнкүрештә урнаштыру;

медицина ярдәме күрсәтү;

психологик ярдәм күрсәтү;

югалган туганлык һәм башка социаль элемтәләрне торгызуда булышлык күрсәтү;

ирективн мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүнең башка формалары.

2.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары белән, граждан җәмгыяте институтлары белән, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән ирекләреннән мәхрүм ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләре буенча эшчәнлекне координацияләүне һәм аларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның Республика регистрында  муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Кабат җинаятьчелекне  (рецидивны) кисәтү.

2.5. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә үткәрелә торган, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү һәм хезмәт реинтеграциясе эшләре турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итү.

## III. Ведомствоара комиссиянең вәкаләтләре

Аңа йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында ведомствоара комиссия түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

3.1. Шәхси тәртиптә яңадан со-социальләштерүгә ярдәм күрсәтүгә ризалык килгән затларның социаль хәлен карый һәм анализлый.

3.2. Законда каралган дәүләт һәм муниципаль ярдәм механизмнарын, башка оешмаларның һәм граждан җәмгыяте институтларының мөмкинлекләрен исәпкә алып, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затны яңадан социальләштерүнең шәхси программасын эшли. Тернәкләндерү (реабилитация) программасында каралган һәр чараны тормышка ашыру өчен җаваплы затларны, аларны гамәлгә ашыру вакытын билгели.

3.3. Яңадан социальләштерү буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләрен һәм нәтиҗәлелеген анализлый.

3.4. Яңадан социальләштерүнең шәхси программасын түбәндәге очракларда гамәлгә ашыруны туктату турында карар кабул итә:

тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешү;

затның Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы чикләреннән даими яшәү урынына китүе (затның Татарстан Республикасы чикләрендә башка муниципаль районга (шәһәр округына) киткән очракта күрсәтелгән факт турында мәгълүмат затка карата булган материаллары белән бергә тиешле муниципаль районның (шәһәр округының) ведомствоара комиссиясенә җибәрелә);

затның яңадан социальләштерүдән баш тарту турында гаризасы керүе;

яңадан социальләштерүнең шәхси программасын алга таба гамәлгә ашыру мөмкинлеген юкка чыгара торган башка очраклар.

3.5. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында кабат җинаятьчелекне (рецидивны) профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.6. Ведомствоара комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

3.6.1. Үз компетенциясе кысаларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан башкаруга тәкъдим ителгән карарларны кабул итәргә;

3.6.2. Аны бозганга җинаять яки административ җаваплылыкка тартылу каралган закон бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү өчен хокук саклау органнарына тиешле документларны һәм материалларны җибәрергә.

3.7. Ведомствоара комиссия үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән үзара эш итә:

3.7.1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе җәзаларны үтәтү Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

3.7.2. Эчке эшләр органнары белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

шәхси профилактик эш үткәрү;

хокукый белемнәрне алга сөрүдә (пропагандалауда) катнашу;

3.7.3. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләр (социаль яклау бүлекләре, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре) белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру кысаларында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга матди ярдәм күрсәтү;

билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, социаль хезмәт алучы затлар белән профилактик эш алып бару;

социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче балигъ булмаган балаларны, шулай ук иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарны социаль адаптацияләү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителергә әзерләнүче затларга хезмәт базары, булган вакансияләр турында мәгълүмат бирү юлы белән яңадан социальләштерүгә ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга эшчәнлек (һөнәр) өлкәсендә, эшкә урнаштыру, һөнәри белем бирү максатларында һөнәри юнәлеш буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип

танылган әлеге категория затларга - эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль адаптацияләү, һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

ирекләреннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга туры килерлек эш эзләүдә ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга эш бирүчеләрне кызыксындыру (стимулирование);

3.7.4. Территориаль сәламәтлек саклау идарәсе (булган очракта), сәламәтлек саклау учреждениеләре белән беренчел медицина-санитария ярдәмен, профилактик һәм диспансер күзәтүне оештыру мәсьәләләре буенча;

3.7.5. Аларның компетенциясе нигезендә дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары белән.

## IV. Ведомствоара комиссияне формалаштыру тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында формалаша.

Ведомствоара комиссия рәисе:

Ведомствоара комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

Ведомствоара комиссия утырышларын алып бара, хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия;

Ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына үз вәкаләтләре кысаларында йөкләмәләр бирә;

Ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән документларга кул куя;

Ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен шәхси җаваплылык тота.

Ведомствоара комиссия секретаре:

Ведомствоара комиссия рәисе күрсәтмәләрен үти;

Ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга Ведомствоара комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына җәза үтәү системасы администрацияләреннән керә торган затның азат ителүе, аның торагы, эшкә сәләте һәм булган белгечлекләре турында мәгълүматны җыюны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан яңадан социальләштерүгә ярдәм итү турында гаризалар кабул итә;

яңадан социальләштерү программасының һәр катнашучысына күзәтү картасын (карта сопровождения) һәм яңадан социальләштерүнең шәхси

программасы чараларын үтәү буенча документлар һәм белешмәләр кергән шәхси эшне (личное дело) рәсмиләштерә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның Республика регистрының муниципаль сегментын алып бара;

Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан, вазыйфаи затлардан ведомствоара комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны соратып ала;

Ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

Ведомствоара комиссия утырышлары нәтиҗәләре буенча бирелгән Ведомствоара комиссия рәисе күрсәтмәләрен үтәүне оештыра;

Ведомствоара комиссия функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы халкына мәгълүмат җиткерүне оештыра.

4.2. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

4.3. Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, мәгариф оешмалары вәкилләре керә ала (килешү буенча).

4.4. Ведомствоара комиссия составына элек иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, яңадан социальләштерү буенча уңай тәҗрибәсе булган затлар да кертелергә мөмкин.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышларында Балтач районы прокуратурасы вәкиле катнашырга хокуклы (килешү буенча).

4.6. Ведомствоара комиссия утырышыларына ведомствоара комиссия составына кермәгән дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырыла ала.

4.7. Ведомствоара комиссия эшендә катнашу иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

## V. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эше даими нигездә алып барыла.

5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан яңадан социальләштерүгә ярдәм итү турында гаризалар керүгә карап, ләкин айга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә үткәрелә. Кирәк булган очракта, Ведомствоара комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук ведомствоара комиссия әгъзасы (комиссия рәисе белән килешенеп һәм ведомствоара комиссия секретаре тәкъдиме буенча) инициативасы буенча Ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.3. Ведомствоара комиссия утырышын Ведомствоара комиссия рәисе алып бара, ә ул булмаганда яки аның кушуы буенча – ведомствоара комиссия рәисе урынбасары.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында яңадан социальләштерүгә ярдәм күрсәтү турында гариза керткән затларга, аларның туганнарына, утырышларда катнашулары максатка ярашлы дип танылган башка затларга утырыш көненә кадәр бер тәүлек кала вакыттан да соңа калмыйча хәбәр ителә.

5.5. Ведомствоара комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында Балтач районы прокурорына хәбәр ителә.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы аның составының яртысыннан күбрәге катнашу шарты белән тулы хокуклы булып тора.

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары тәкъдим итү характерына ия һәм ачык тавыш бирү юлы аша утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.8. Ведомствоара комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.

5.9. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән зат теләге буенча утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча уздырыла.

5.10. Ведомствоара комиссия әгъзалары комиссия утырышында тикшерелгән мәсьәләләр турында мәгълүматларны әлеге мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка таратырга хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматларны тараткан өчен ведомствоара комиссия әгъзалары закон нигезендә җавап тота.

5.11. Ведомствоара комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатында, ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат бирү рөхсәт ителә.